**Казан шәһәре Думасының**
**2024 елның 18 декабрендәге 6-35 номерлы карары**

**Казан шәһәре Думасының 2009 елның 12 мартындагы 11-39 номерлы «Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының муниципаль вазифаларын даими нигездә биләүче затларга хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының муниципаль вазифаларын даими нигездә биләүче затларга социаль гарантияләрне тәэмин итү максатыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы “Татарстан Республикасындагы җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазифаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карарына таянып, Казан шәһәре Думасы **карар бирде**:

1. Казан шәһәре Думасының 2009 елның 12 мартындагы 11-39 номерлы «Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының муниципаль вазифаларын даими нигездә биләүче затларга хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары турында»гы карарына (Казан шәһәре Думасының 2010 елның 27 мартындагы 19-1 номерлы, 07.06.2012 елның 21-14 номерлы, 2012 елның 24 октябрендәге 9-17 номерлы, 2013 елның 14 мартындагы 14-21 номерлы, 2013 елның 16 октябрендәге 16-25 номерлы, 2014 елның 28 августындагы 5-35 номерлы, 2014 елның 3 октябрендәге 29-36 номерлы, 2017 елның 17 августындагы 11-19 номерлы, 2018 елның 17 апрелендәге 13-25 номерлы, 2019 елның 20 июнендәге 15-34 номерлы, 2020 елның 21 сентябрендәге 20-1 номерлы, 2022 елның 13

октябрендәге 3-17 номерлы, 2022 елның 19 декабрендәге 22-19 номерлы, 2024 елның 26 июнендәге 5-30 номерлы, 2024 елның 7 августындагы 7-31 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 номерлы кушымтаны әлеге карарның кушымтасы нигезендә редакцияләргә;

1.2. 5 номерлы кушымтада:

1.2.1. 1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Эш нәтиҗәләре буенча премия билгеле бер эш периоды өчен (ай, квартал, ел) бер тапкыр түләнә ала»;

1.2.2. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3. Премия күләме премияне исәпләү өчен хезмәт өчен түләү күләменнән чыгып яки абсолют күләмдә (сумнарда) билгеләнә»;

1.2.3. түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

«4. Премия исәпләү өчен хезмәт өчен түләү күләменә түбәндәге түләүләр керә:

- айлык акчалата түләүләр;

- айлык акчалата түләүләр;

- нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен айлык компенсация түләве;

- дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен айлык акчалата түләүләргә айлык өстәмә түләүләр;

- профильле фәнни дәрәҗә өчен айлык өстәмә түләүләр;

- Татарстан Республикасының мактаулы исеме өчен айлык өстәмә түләүләр».

2. Әлеге карар, рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә торган һәм 2024 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә тәэсир итә торган 1.2.1, 1.2.2, 1.2.3 пунктларыннан тыш, 2025 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының
2024 елның 18 декабрендәге
6-35 номерлы карарына
кушымта

**Айлык акчалата түләү күләмнәре**

Муниципаль вазифаларны даими нигездә биләүче затларга айлык акчалата түләү түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| № т/б | Муниципаль вазифа исеме | Айлык акчалата түләү күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | Муниципаль берәмлек башлыгы – Казан шәһәре Мэры | 51026 |
| 2 | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башлыгының беренче урынбасары | 45923 |
| 3 | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башлыгы урынбасары | 45923 |
| 4 | Казан шәһәре Думасы секретаре | 41328 |
| 5 | Казан шәһәренең Контроль-хисап палатасы рәисе | 45923 |
| 6 | Казан шәһәренең Контроль-хисап палатасы рәисе урынбасары | 43084 |
| 7 | Казан шәһәренең Контроль-хисап палатасы аудиторы | 34694 |

**Башлык урынбасары** **Е.А.Лодвигова**